МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**29.06.2023** Казан ш. **№142**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 11 октябрендәге 399 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 11 октябрендәге 399 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2023 елның 9 мартындагы 55 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва белдерүчеләрнең һөнәри дәрәҗәсен бәяләүдән, аларның әлеге вазыйфаны биләү өчен билгеләнгән башка квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү һәм шундый бәяләү һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп кую өчен

дәгъва белдерүчеләр арасыннан кандидатлар арасыннан гражданинны яки граждан хезмәткәрен билгеләүдән гыйбарәт.»;

1.6 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«министр карары буенча граждан хезмәте вазыйфаларының кече төркеменә караган граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләнгәндә, шулай ук федераль законнарда каралган башка очракларда.»;

2.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс комиссиясе шулай ук тәкъдим холкына ия булган, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен конкурста җиңмәгән, ләкин профессиональ дәрәҗәсе, һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган кандидатны дәүләт органының кадрлар резервына кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге кандидатның ризалыгы белән, ул Министрлыкның кадрлар резервына кертелергә мөмкин».

3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Гражданин (граждан хезмәткәре) конкурста катнашуга кертелми:

а) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата, граждан хезмәте стажына яки белгечлек буенча эш, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләренә туры килмәве сәбәпле;

б) белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (белгечлек һәм әзерлек юнәлешләренең зурайтылган төркемнәренә), һөнәри яңадан әзерлекнең өстәмә һөнәри программасын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификациягә карата квалификация таләпләренә (граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләрендә шундый таләпләр каралган очракта) туры килмәве сәбәпле;

в) граждан хезмәтенә керү һәм аны узуга бәйле чикләүләргә һәм Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында законнарына бәйле рәвештә.»;

3.5 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«белем һәм (яки) квалификация турында документлар күчермәләре, шулай ук гражданинның теләге буенча хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте тарафыннан расланган гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турындагы документлар күчермәләре;»;

4.4.1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге:

кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшерә:

гражданинның (граждан хезмәткәренең) һөнәри белем дәрәҗәсенә, граждан хезмәте стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше, һөнәри дәрәҗәгә квалификация таләпләренә, шулай ук, министрның тиешле карары булганда – өстәмә яңадан һөнәри әзерлек үзләштерү нәтиҗәләре буенча белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (эреләндерелгән белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре төркемнәренә карата), квалификациягә карата таләпләргә туры килүен тикшерә.»;

4.4.6 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгәр конкурс нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен кирәкле һөнәри дәрәҗәгә ия булган кандидатлар ачыкланмаса, яллаучының вәкиле кабат конкурс үткәрү турында карар кабул итә ала.»;

4.4.7 пунктның икенче абзацын түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү;»;

4.4.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс уздырганда конкурс комиссиясе кандидатларны белеме һәм (яки) квалификация турында, граждан яки башка дәүләт граждан хезмәтен үтү, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турында алар тарафыннан тапшырылган документларга нигезләнеп, шулай ук конкурс процедуралары нигезендә, шул исәптән кандидатлар биләү өчен дәгъва белдерә торган граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча вазыйфа бурычларын үтәүгә бәйле мәсьәләләрдә, шәхси әңгәмә коруны, анкета сорауларына җавап алуны, тест уздыруны да кертеп, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килми торган, кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын һөнәри дәрәҗәдәге бәяләү методларын кулланып бәяли.»;

4.4.8.2 пунктның өченче абзацында «комиссия бәяли» сүзләреннән соң «һөнәри дәрәҗә, » сүзләрен өстәргә;

4.8 пунктның икенче абзацында «граждан хезмәте, әмма» сүзләреннән соң «һөнәри дәрәҗә,» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге боерыкның гамәлдә булуы 2023 елның 29 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **М.Р.Шаһиәхмәтов**